ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; 10), аңа түбәндәге эчтәлекле $11^2$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$11^2$ статья. **Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә йөрүче һәм мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләнү яисә әйләнә-тирә мохиттә ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтелүгә мохтаҗ булмаган затларга хезмәтләр күрсәтү**

1. Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә йөрүче һәм мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләнү яисә әйләнә-тирә мохиттә ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтелүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә вакытлыча тоту хезмәтләре күрсәтелә.

2. Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә йөрүче һәм мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләнү яисә әйләнә-тирә мохиттә ориентлашу сәләтен югалткан затларның медицина ярдәме күрсәтелүгә мохтаҗлыгын медицина оешмалары тарафыннан билгеләү федераль норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Махсуслаштырылган учреждениеләрдә вакытлыча тоту хезмәтләре Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләрендә күрсәтелә: Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Азнакай муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Чистай муниципаль районы.

4. Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә йөрүче һәм мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләнү яисә әйләнә-тирә мохиттә ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтелүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Җәмәгать урыннарында исерек хәлдә йөрүче һәм мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләнү яисә әйләнә-тирә мохиттә ориентлашу сәләтен югалткан, медицина ярдәме күрсәтелүгә мохтаҗ булмаган затларга махсуслаштырылган учреждениеләрдә хезмәт күрсәтү вәкаләтләре федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарына тапшырыла ала.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 10 июль
№ 51-ТРЗ